***Заһидуллин Харис Һидиятулла улы***



*Мин, Заһидуллин Харис Һидиятулла улы, 1940 нчы елның 15 нче маенда туганмын. Сугыш башланганда мина 1 яшь тә 1 ай булган. Мин бишектә булганмын. Әтине сугыш башлангач ук сугышка алганнар. Сугыш елларын мин хәтерләмим. Сугыш башлану белән безгә бик кыен булгандыр. Ашарга, эчәргә бик начар. Бәрәңге игеп, ипи пешерүләр истә калган. Кузгалаклар ашадык, шуннан аш пешердек.*

*Күңелле вакыйгалар булганын хәтерләмим. Сугыш беткәч, 1947 нче елда мәктәпкә 1нче сыйныфка укырга кердем.*

*Хәзерге яшь буынга мин сәламәтлек телим, яхшы укысыннар.*

*Без күргәннәрне алар күрмәсен. Әти-әниләрен тыңласыннар.*